Республика Татарстан
РАНГАЗАРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул.Советская, д.48,
с.Рангазар
Телефон: (85559) 4- 36-54

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РАНГАЗАР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
Совет урамы, 48 йорт,
Рангазар авылы, 423351.
Телефон: 4- 36- 54

ОКПО 93068284 ОГРН 1021601313470 ИНН/КПП 1636001280/163601001

**РЕШЕНИЕ**
**№28**

**КАРАР**
**от 12.12.2019 года**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021-2022 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында**

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021-2022 нче елларның планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» гы мәгълүматны тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021-2022 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге башкарма комитеты Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021-2022 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге Советы Рәисе Г.Б.Бариев

Кушымта 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенен 2020 елга һәм 2021-2022 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2017 Хисап | 2018 Хисап | 2019 Хисап | 2020 Фараз | 2021 Фараз | 2022 Фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халык саны | кеше | 580 | 578 | 578 | 575 | 575 | 575 |
| Темп роста к предыдущему году | % | | | | | | |
| Эре мөгезле терлекләр саны | Баш саны | 375 | 375 | 370 | 370 | 370 | 370 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Инвестицияләр | мең сум | | | | | | |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | 0 | 0 | | |
| Торак төзелеше | кв.м. | 50 | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 3334,4 | 3471,1 | 4578,5 | 5645,2 | 7107,5 | 7863,4 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 27786,8 | 28925,8 | 38154,2 | 47043,3 | 59229,2 | 65528,3 |
| Эшчеләр саны | кеше | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 |
| Эшкуарлар саны (КФХ) | кеше | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Эшсезләр саны | кеше | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |

Рангазар авыл җирлеге баш белгече Сарварова Р.В.

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенен**
**2020 елга һәм 2021-2022 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.
2020-2022 нче елларга Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2020-2022 нче елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең 2019 елның көтелгән нәтиҗәләрен һәм 2020-2022 елларда икътисад һәм социаль өлкәне үстерү тенденцияләрен, 2020-2022 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып, барлыкка килгән социаль - икътисадый үсеш торышын анализлап чыгару максатында, Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә анализ ясалды.
2020-2022 елларда «Urals» нефтькә бәяләр баррель өчен 40-42 АКШ доллары дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана.
2020 елда доллар курсы уртача еллык АКШ доллары өчен 64,9 сум, 2021 елда – 65,4 сум булыр дип фаразлана. 2022 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 66,2 сум тәшкил итәчәк.
Рангазар авыл җирлеге Рангазар, Рантамак, Бал-Тамак авылларыннан тора.
2020 елга Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегендә халык саны – 575 кеше, 2021 елга – 575, 2022 елга 575 кеше тәшкил итәчәк.
Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Агрокөч төркеме» ЯАҖнең «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖенең, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның потенциалын һәм бүгенге үсеш тенденцияләрен, шулай ук «агросәнәгать комплексын үстерү», «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү» һәм «шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү»программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.
Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖ «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ һәм КФХ "Габидуллин" , КФХ "Загриев" эшчәнлеге алып бара.
2020 елга эшмәкәрләр саны 9кеше тәшкил итәчәк, 2021 елга-9, 2022 елга-9 кеше.